ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАГРАЖСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАГРАЖ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.12.2018 ел**

**КАРАР**
**№ 20**

**Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Баграж авыл җирлеге Уставы, «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 12 февралендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар итте:**

1. Баграж авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **П.Н. Минеев**

Зәй муниципаль районы
Баграж авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 27 декабрендәге
20 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Баграж авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары киләсе календар елның 15 февраленә кадәр Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, җирле референдумда (җыенда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан түләнә.

3. Түләми тору өчен нигезле сәбәпләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык (6 айдан артык),

б) оешманы бетерү, оешма хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту сәбәпле эштән азат ителү,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектерү ике айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы турында гражданнарга хәбәр җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру, кул куйдырып, кулга бирү юлы белән җиткерелә, почта элемтәсе аша җибәрелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган документлар булып приход касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Зәй муниципаль районы
Баграж авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 21 декабрендәге
23 номерлы карарына
2 нче кушымта

____________________ авыл җирлеге бюджетына бер тапкыр түләнә торган салымны түләү турында _____ номерлы
ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮ)

Түләүченең
Ф.И.А.____________________________________________________________
Адресы: __________________________________________________________
Сезгә ____________________________________нигезендә _______________
вакытында кадәр ________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча салым түләргә кирәк.
Банк БИК _____________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № _________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләүнең
билгеләнеше__________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________
М.У. (имза) (имза тулысынча)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерү) No ____
_____________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча _________________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А. ___________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
Алынган «__» ________________ 20__ ел___________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Өзеп бирелә торган квитанция тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылганда төпсә_____________авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*